| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>***БУА ШӘҺӘРЕ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ*** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>***ГЛАВА<br>ГОРОДА БУИНСКА<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА*** |

# КАРАР
# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

22 январь 2015 ел № 1

«Капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә
рөхсәт ителгән куллану, рөхсәт ителгән төзелешнең
чикле параметрларыннан тайпылу рөхсәте
мәсьәләләре буенча гавами тыңлаулар
билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында» 2003 елның 06 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Буа шәһәр Советының 1998 елның 18 ноябрендәге 2-29 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районының Буа шәһәрендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Буа шәһәр Советының 1998 елның 18 ноябрендәге 2-29 номерлы «Буа шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» карары нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елның 12 февраленә 10.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәләләр буенча ТР, Буа ш., Р. Люксембург ур., 51 йорт (Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасы) адресы буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:

1.1. ТР, Буа ш., Р. Люксембург ур., 169 адресы буенча урнашкан 28 кв. м. мәйданлы 16:14:990117:602 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, җир кишәрлеген куллануның шартлыча югарыда күрсәтелгән төренә (кибеткә) рөхсәт бирү турында.

1.2. ТР, Буа ш., Яшел ур., 37 адресы буенча урнашкан 1557 кв. м. мәйданлы 16:14:990163:96 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, җир кишәрлеген куллануның шартлыча югарыда күрсәтелгән төренә (индивидуаль торак йорт ) рөхсәт бирү турында.

2. Капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча эш төркеме формалаштырырга. (1 нче кушымта).

3. Капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә куллану, рөхсәт ителгәннәрнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар 2015 елның 5 февраленә кадәр (кертеп) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422430, Буа ш., Р. Люк-

сембург ур., 51, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шимбә көнне- 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Буа шәһәре башлыгы А.К. Айзетуллов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Буа шәһәре башлыгының
2015 елның 22 гыйнварындагы
1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә
рөхсәт ителгән куллану, рөхсәт ителгән төзелешнең
чикле параметрларыннан тайпылу рөхсәте
мәсьәләләре буенча гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру
буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Никифоров Александр Александрович | Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, эш төркеме рәисе (килештерү буенча) |
| Зайцева Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгы урынбасары, эш төркеме рәисе урынбасары |
| Гыйлфанов Ринат Мансур улы | Буа районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге башлыгы, эш төркеме рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| Эш төркеме әгъзалары: | |
| Гыйззәтов Илдус Гашыйк улы | Буа районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча беренче урынбасары (килештерү буенча) |
| Әхмәтҗанов Азат Фазылҗан улы | Буа муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Мифтахов Фәнис Фариз улы | Буа район Советының юридик бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| Сөнгатов Вәгыйз Сәгыйть улы | Буа шәһәр Советының Төзекләндерү, архитектура һәм төзелеш буенча даими комиссия рәисе (килештерү буенча) |